ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**«Гражданнарның торак хокукларын яклауны тәэмин итү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2018 елның 21 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

«Гражданнарның торак хокукларын яклауны тәэмин итү турында» 2011 елның 10 октябрендәге 72-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2011, № 10 (I өлеш); 2012, № 11 (I өлеш); 2015, № 4; 2016, № 7 – 8; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 27 (I өлеш), № 94 ( I өлеш); 2018, № 29 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяның 2 өлешендә «Татарстан Республикасы дәүләт торак күзәтчелеге органының» сүзләрен «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең республика дәүләт торак күзәтчелеген гамәлгә ашыручы вәкаләтле башкарма органының» сүзләренә алмаштырырга;

2) 3 статьяда «Россия Федерациясе Бюджет кодексы,» һәм «Татарстан Республикасы Бюджет кодексы,» сүзләрен төшереп калдырырга;

3) 4 статьяның 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«2) Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең республика дәүләт торак күзәтчелеген гамәлгә ашыручы вәкаләтле башкарма органын (алга таба – Татарстан Республикасы дәүләт торак күзәтчелеге органы) билгеләү;»;

4) 5 статьяның 1 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«1. Татарстан Республикасы дәүләт торак күзәтчелеге органы гражданнарның торак хокукларын яклауны тәэмин итү өлкәсендә Россия Федерациясе Торак кодексының 20 статьясы нигезендә республика дәүләт торак күзәтчелеген гамәлгә ашыра.»;

5) 6 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6 статья. **Гражданнарның торак хокукларын яклауны тәэмин итү өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең бүтән башкарма органнары вәкаләтләре**

Гражданнарның торак хокукларын яклауны тәэмин итү өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары үз компетенциясе чикләрендә түбәндәге вәкаләтләрне гамәлгә ашыралар:

1) электр энергетикасы, җылылык белән тәэмин итү, газ белән тәэмин итү, су белән тәэмин итү һәм ташландык суны җибәрү, каты көнкүреш калдыклары белән эш итү өлкәләрендә бәяләрне (тарифларны) законнар нигезендә җайга салу;

2) торак урыннарда коммуналь хезмәтләр күрсәтүдән файдалану нормативларын, күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне карап тоту максатларында салкын судан, җылы судан файдалану, агып төшкән суны җибәрү, электр энергиясен куллану нормативларын, җир кишәрлегеннән һәм ишегалды корылмаларыннан файдаланганда коммуналь хезмәтләр күрсәтүдән файдалану нормативларын билгеләү;

3) дәүләт тарафыннан җайга салына торган бәяләр (тарифлар) өлкәсендә төбәк дәүләт тикшереп торуын (күзәтчелеген) законнарда билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашыру;

4) коммуналь хезмәтләр күрсәткән өчен гражданнар тарафыннан кертелә торган түләү күләме үзгәрүнең иң чик (максималь) индекслары кулланылуга мониторинг ясауны гамәлгә ашыру;

5) законнар нигезендә башка вәкаләтләр.»;

6) $6^2$ статьяда:

а) исемдә «Республика дәүләт торак күзәтчелеге» сүзләрен «Татарстан Республикасы дәүләт торак күзәтчелеге» сүзләренә алмаштырырга;

б) 1 өлешнең 2 пунктында «күзәтчелегенең вәкаләтле» сүзләрен «күзәтчелеге» сүзенә алмаштырырга;

7) 7 статьяның 1 өлешендәге 5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5) Россия Федерациясе Торак кодексында каралган очракларда һәм тәртиптә күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләренең җыелышларын җыялар;»;

8) 8 статьяны үз көчен югалткан дип санарга;

9) 10 статьяда:

а) 2 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Күпфатирлы йортлар белән идарә итү өлкәсендә үз-үзен җайга салучы оешмалар күпфатирлы йортлар белән идарә итү стандартларын эшләргә һәм расларга мөмкин.»;

б) 3 өлештә «үз-үзен җайга салуның үсешенә булышлык күрсәтәләр» сүзләрен «үз-үзен җайга салучы оешмалар белән үзара хезмәттәшлек итәләр» сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН *
ГОМУМИ
БҮЛЕК
ОБЩИЙ
ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2018 ел, 06 июль
№ 49-ТРЗ